**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**

Урсай авылы № 152 «24» сентябрь 2019 ел

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Урсай авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 350 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан түләүне киметеп, аны 175 сум (50%) күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга щебенка җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) Гастелло ур.; Джалиль ур., Урсай авылы; Такташ ур.,Мөслим авылы;
- Урсай һәм Мөслим авылларында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Урсай һәм Мөслим авылларында территориядә җыештыру, көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны вакытлыча җыю, чистарту;
- Урсай авылында зиратларны койма белән әйләндереп алу өчен материал сатып алу;
- Урсай һәм Мөслим авылларда юлларны кардан чистарту;
- Урсай һәм Мөслим авылларда җәй көне территорияне чабу;
- Урсай һәм Мөслим авылларында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Урсай һәм Мөслим авылларында артезиан скважиналарына насослар сатып алу.

- Урсай һәм Мөслим авылларында урам күрсәткечләрен ике телдә ясау һәм урнаштыру.

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Урсай авылы, Үзәк ур., 65 йорт; Мөслим авылы, Гафури ур., 31 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Рәис И.А.Абдуллин